*Урманнар, кырлар ап-ак юрган белән капланды.*

# ТЕСТ

**1.Сыйфатлар нәрсә белдерә?**
**а) предметны; б) предметның эшен; в) предметның билгесен;**
**2. Сыйфатларга нинди сораулар куела?**
**а) кем? нәрсә?; б) нинди? кайсы?; в) нишли? нишләде?;**
**3. Сыйфатлар нәрсәгә бәйләнеп килә?**
**а) исемгә; б) фигыльгә; в) кисәкчәләргә;**
**4. *Уңган* сүзенә синоним сыйфат табыгыз:**
**а) ялкау; б) шаян; в) өлгер;**
**5. *Киң* сүзенә антоним сыйфат табыгыз:**
**а) кыска; б)тар; в)кечкенә;**
**6. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар булган рәтне билгелә:**
**а)ал, кызыл; б)зәңгәррәк, аграк; в)саргылт, яшькелт.**

# Тестның җаваплары

**1 в) предметның билгесен;**

2. **б) нинди? кайсы?;**

3. **а) исемгә;**

4. **в) өлгер;**

5. **б) тар;**

**6. б)зәңгәррәк, аграк;**

Кышкы урманның үз яме бар. Кояшлы жилсез иртәләрдә ул бик матур. Зәңгәрсу күктән елмаеп торган саргылт кояш нурында ап-ак кар бөртекләре җемелдиләр.

Урмандагы ямь-яшел киемнәргә төренеп, шаулап торган агачлар хәзер тирән уйга талган кебек тып-тын.

кышкы кояшлы җилсез бик матур зәңгәрсу ап-ак

у **АСЫЛ** ямь-яшел тирән тып-т **Нисби**

# СЫЙФАТ

| АСЫЛ | НИСБИ |
| --- | --- |
| *предметның төп билгесен белдерә* | *предметның башка предмет аша билгесен ачыклыйлар* |
| *дәрәҗәгә куела* | *дәрәҗәгә куелмый* |
| *ясалышы: тамыр, ясалма* | *ясалышы: ясалма* |









Ап-ак тун киеп кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава.
Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк –
Безнең иң якын дуслар



**Алдагы дәрес өчен проблемалы сорау**

*Алсу матур күлмәк кигән.*
*Алсуның күлмәге матур.*



# Өй эше:

- Дәреслек, 6нчы күнегү,сыйфатларны язып алып, дәрәҗәләрен һәм төрен билгеләргә;
- Иҗади эш:1үк сыйфат үзе ачыклап килгән сүзнең алдында да,артында да торган 2 шәр җөмлә төзергә.

# Бәяләү критерийлары

Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам –



Теманы аңладым, ләкин бераз каушап калам –



Тема авыррак булды-

